# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Яңа Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Варклед-Авыл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

24.11.2023 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының районының «Яңа Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Варклед-Авыл торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2023 елның 24 октябрендә 09:00 сәг уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2024 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Яңа Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Варклед-Авыл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан һәм Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, ирекле киткән) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатыннарын, балигъ булмаган балаларын) түләүдән азат итү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Урам яктырту челтәрләрен ремонтлау (электротоварлар сатып алу һәм лампаларны, фонарьларны алыштыру һәм хезмәт килешүе буенча электрикка хезмәт хакы түләү).

2. Су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аларны чистарту, транспортировкалау һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженер корылмаларын төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү системалары өчен материаллар һәм электр товарлары сатып алу).

3. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Варклед-Авыл торак пункты янәшәсендәге урман буендагы җир кишәрлекләре янәшәсендәге урыннарда үлән чабу һәм янгынга каршы минерализацияләнгән полосаларны сөрү һәм ягулы-майлау материаллары сатып алу).

4. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (үлән чабу һәм торак пункт урамнарын кардан чистарту)

5. Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау һәм алар тирәсендәге территорияләрне төзекләндерү (Беларус-82.1 тракторын карап тоту һәм хезмәт күрсәтү ( запас частьләр, дизель ягулыгы алу һәм штаттан тыш хезмәткәргә хезмәт килешүе буенча хезмәт хакын түләү, трактор өчен өстәмә асылма җиһазлар сатып алу); кешеләрнең тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч янаучы авария һәм коры яшеллек утыртмаларын кисү).

6. Традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү (зиратның хуҗалык блогын ремонтлау).

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 29 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 16 кеше, бу 55,17 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 16 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Яңа Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Варклед-Авыл торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. 2024 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Яңа Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Варклед-Авыл торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан һәм Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылардан (хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгән, ирекле киткән) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (бергә яшәүче ата-аналарыннан, хатыннарыннан, балигъ булмаган балаларыннан) тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

– Урам яктырту челтәрләрен ремонтлау (электротоварлар сатып алу һәм лампаларны, фонарьларны алыштыру һәм хезмәт килешүе буенча электрикка хезмәт хакы түләү).

– Су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аларны чистарту, транспортировкалау һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженер корылмаларын төзү һәм ремонтлау,

проектлау (су белән тәэмин итү системалары өчен материаллар һәм электр товарлары сатып алу).

– Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Варклед-Авыл торак пункты янәшәсендәге урман буендагы җир кишәрлекләре янәшәсендәге урыннарда үлән чабу һәм янгынга каршы минерализацияләнгән полосаларны сөрү һәм ягулы-майлау материаллары сатып алу).

– Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (торак пункт урамнарын кардан чистарту)

– Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау һәм алар тирәсендәге территорияләрне төзекләндерү (Беларус-82.1 тракторын карап тоту һәм хезмәт күрсәтү (запас частьләр, дизель ягулыгы алу һәм штаттан тыш хезмәткәргә хезмәт килешүе буенча хезмәт хакын түләү); үлән чабу һәм кешеләрнең тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч янаучы аварияле һәм коры яшеллек утыртмаларын кисү).

– Традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү (зиратның хуҗалык блогын ремонтлау).

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы М.С. Салихов